СОВЕТ ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                    КАРАР

08.11.2024 ел          с. Шеланга          № 42-231

Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы авылы торак пункты территориясенең бер өлешендә үзара салым кертү һәм аннан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә 2024 елның 29 ноябренә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Шилангы торак пункты территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 5150 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
- Шилангы торак пункты Мәктәп урамын төзекләндерү

«ӘЙЕ»                                        «ЮК»

3. Халык җыенын йорт янындагы территориядә түбәндәге адрес буенча уздырырга: Шилангы авылы, Мәктәп урамы, 38 йорт 16:30 сәгатьтә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шилангы авыл җирлеге Башкарма

комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров